СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е**

**К А Р А Р**

**7 ноябрь 2023 ел** Болгар ш. **№ 33-2**

2013 елның 18 февралендәге «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вазифаи затларын һәм муниципаль хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 29-3 номерлы ТР Спас муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 30 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 27 статьясы, «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләрен командирлау тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2016 елның 29 декабрендәге 14-2 номерлы карары белән Спас муниципаль районы Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2013 елның 18 февралендәге «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вазифаи затларын һәм муниципаль хезмәткәрләрен командировкалау тәртибе һәм шартлары турында» 29-3 номерлы ТР Спас муниципаль районы Советы карарына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 нче пунктта «көненә 1200 сумнан артык түгел» дигән сүзләрне «көненә 2400 сумнан артык түгел» дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны финанс-бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының spasskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Спас муниципаль районы Башлыгы,
Советы Рәисе Ф. В. Мөхәммәтов